**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
**III чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йортТел. 3-44-44,факс3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**III созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/.3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
от 09.11.2019г

**РЕШЕНИЕ**
№41-10

Актаныш муниципаль район Советының 2014 елның 7 февралендә кабул ителгән 36-01 санлы “Актаныш муниципаль район Советы регламенты турында " карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү максатыннан 25.12.2008 ел, №273-ФЗ “Коррупциягә каршы көрәш турында” гы Федераль законның 15 нче маддәсенә ярашлы рәвештә, Актаныш муниципаль районы Советы

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2019 елның 20 февралендәге Карары белән расланган социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмаларга биләмәгә һәм (яки) файдалануга бирелә торган муниципаль мөлкәт исемлеген (коммерцияле булмаган оешманың мөлкәти хокукларыннан тыш) алып бару, бастырып чыгару регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 25 маддәнең 6 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- “6. Гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрнең кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы карарлар рәсми бастырып чыгарылганнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.”

1.2. 40 маддәне түбәндәге редакциядә бирергә:

“40 маддә. Район Советы эше турында мәгълүмат

1. Муниципаль район Советы утырышлары ачыктан-ачык үткәрелә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында киң яктыртылырга һәм "Интернет" челтәрендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының рәсми порталында урнаштырылырга тиеш.

Муниципаль район Советы эше, аның булачак утырышларының вакыты һәм урыны турында һәм ул кабул иткән карарлар турында район халкына массакүләм мәгълүмат чаралары аша җиткерелә һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы җирле үзидарә органнарының “Интернет” челтәрендә рәсми порталында мәгълүмат урнаштырылырга тиеш".

2. Гражданнарга (физик затларга) һәм оешмалар вәкилләренә муниципаль район Советының ачык утырышларында, шул исәптән муниципаль район Советы утырышының көн тәртибендәге аерым мәсьәләләр буенча да, катнашу мөмкинлеге тәэмин ителә.

Муниципаль район Советы утырышында катнашу нияте турындагы язма гаризалар

тәртибен бастырып чыгарганнан соң муниципаль район башлыгы исеменә җибәрелә, муниципаль район Советы утырышына өч көннән дә соңга калмыйча анда катнашу ниятен белдерә.

Муниципаль район Советы утырышларында оешма вәкилләренең катнашуы муниципаль район башлыгы исеменә җибәрелгән җитәкчеләрнең язма гаризалары нигезендә, муниципаль район Советы утырышына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, вәкилнең фамилиясен, исемен, атасының исемен, аның контакт телефоннарын, паспортның сериясен һәм номерын, шәхесен таныклаучы башка документ номерын күрсәтеп гамәлгә ашырыла.

3. Гражданнарның (физик затларның) һәм оешма вәкилләренең муниципаль район Советының утырышлар залында булу мөмкинлеген тәэмин итү өчен биш урынга кадәр бирелә.

Муниципаль район Советы утырышында катнашырга теләк белдергән гражданнар (физик затлар) һәм оешмалар вәкилләре саны билгеләнгән урыннар саныннан артып китсә, муниципаль район Советы утырышында катнашырга теләк белдергән гражданнар (физик затлар) һәм оешмалар вәкилләре исемлеге муниципаль район Советы аппараты белән аныклана. Муниципаль район Советы утырышында беренче булып гариза биргән затлар катнаша ала. Муниципаль район Советы утырышында катнашырга теләк белдергән гражданнар (физик затлар) һәм оешма вәкилләре муниципаль район Советы утырышына кадәр булган көнгә телефон аша хәбәр ителә.»;

1.3. 4 маддәнең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

- «3. Совет утырышында җәмәгать оешмалары, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре катнашырга хокуклы, алар регламент нигезендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органы тарафыннан раслана.

2. Әлеге карарны Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында веб-адрес буенча http://aktanysh.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә игълан итәргә.

Актаныш муниципаль районы Совет рәисе Э.Н. Фәттахов